БӘЙДӘН ЫЧКЫНСА БӘЯ

Татарстанда яңа төзелүче йортларның 74 проценты сатылмаган

> 2

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ

«Булсын»нарга алданып, «бар»ның кадерен белми калабыз

> 4

ДИЛИЯР БОРҺАНОВ:

«Татарда юмор бар, ләкин көлдерми»

> 4

АВЫЛ КӘЕФЕ

«Быел безнең шәхси хуҗалык көтүен көтәргә кеше юк...»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 54 (29021) | Шимбә | 15 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ИРТӘ КИРӘКМИ КӨТӘРГӘ

БЫЕЛ БӘРӘҢГЕНЕ КАЙЧАН УТЫРТУ ЯХШЫ?

Авыл капкасы

Язның ашкынып килүен исәпкә алып, быел бәрәңгене иртә утыртучылар да бар. Шул ук вакытта «җир өлгермәгән әле, кая ашыгырга?» дип сабыр итүчеләр дә күп. Бәрәңгене кайчан һәм нинди сортларын утыртсак оттырмабыз? Белгечләрдән шул хакта сораштык.

Буада яшәүче һәвәскәр бакчачы Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов бәрәңгене апрель башында ук утыртып куйган инде. Тик монда сүз иртә өлгерә торган сорт турында бара.

– Мин ел саен бәрәңгене иртә утыртам. Узган елларда, гадәттә, апрель ахырлары була торган иде. Быел, яз алданрак килүне искә алып, тагын да иртәләдем: бәрәңгене апрель башында ук утырттым. Дөрес, бу тиз өлгерә торган сорт һәм өч кенә бураэнага чәчтем. Аны тишелеп чыкканнан соң, 35–40 көннән ала башларга була. Ә үзе тулысынча 80 көндә өлгерә.

Тик август – сентябрь башларында ала торган бәрәңгене утыртыр өчен иртә әле, ди Мөхәррәм абый.

– Төп бәрәңге утыртылырга тиешле 2 сутый җирне дә эшкәртеп, әзерләп куйдык. Орлыклык бәрәңгене җылы һәм кояшлы урынга күзәнәк җибәрсен өчен чыгардык. Шуңа күрә, «икенче икмәк»не кайчан утырту яхшы, дигән сорауга бер яклы гына җавап биреп булмый. Аны нинди максаттан утыртудан тора. Сатар өчен кирәк икән, хәзер утыртсалар да була. Ә төп бәрәңгене, елдагыча, май башларында утырту яхшы булыр, чөнки суыклар булмаса да, аны кышка саклыйсы бар бит әле, – диде Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов.

Оста бакчачы әйтүенчә, бәрәңгене утыртканчы, аны яхшылап җылытырга, күзәнәк җибәрттерергә кирәк. Ул 15 көн эчендә шытып кына калмыйча, кечкенә үсентеләр җибәрергә дә өлгерә.

– Менә шундый бәрәңге салкын көндә дә тишелеп чыга. Казан арты районнары белән чагыштырганда, безнең якларда җир иртә өлгерә. Әгәр яшел үлән тишелеп чыккан, карлыган, кура җиләге яфрак җибәргән икән инде, җир җылынган дигәнне аңлата, – ди ул.

Сортларга килгәндә, бакчачы фикеренчә, быел корылык булу ихтимал. Язын да март ахырыннан бирле нык-лап яңгыр яуганы юк. Шуңа күрә бәрәңгенең корылыкка чыдам сортларын сайларга кирәк.

– Әлегә минем өчен уңышлы сорт – «Ажур». Ул корылыкка да чыдам, кышны да яхшы чыга. Бозылганы да, үргәне дә юк. Базда кышлап, тәме дә яңа бәрәңгенеке сыман кала. Быел бәрәңге мәйданым 20шәр метрлы 20 бураэна булачак. Шуның күпчелек өлешен «Ажур» алып торачак. Бераз «Лидер» сортын да утыртам. Ул да – яхшы сорт, «Ажур»дан 3–4 көн алданрак өлгерә, тик дым ярата, – диде бакчачы.

Бәрәңгесе генә түгел, кишер белән суганы да җир куенына кереп урнашкан инде Мөхәррәм абыйның.

bigstockphoto.com

– Суганның «Стурон» сортын икенче ел утыртабыз, – ди ул. – Узган ел «Геркулес» белән икесе дә зур уңыш бирделәр. Суган әле дә бик яхшы хәлдә.

Утыртканчы, орлыкның башларын кисеп, 1 аш кашыгы тоз эретелгән 1 литр суда 3–4 сәгать тотарга, аннан соң юып киптереп алырга кирәк.

Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче Рәис Шәкүров бәрәңге утыртырга ашыкмаска киңәш итә.

– Салкыннар булачак әле. Минем күзәтүләремчә, быел бәрәңгене 11–15 майда утырту яхшы. Минем үземнән дә быел күпләр: «25 апрельдә утыртсак булырмы икән?» – дип сорады. Тик яз ике атнага иртә килде дип, ашыгырга кирәкми. 25 апрельдә утыртсаң да, бүген утыртсаң да, 11 майда кереп урнашса да, бәрәңге барыбер 25 майда гына тишелеп чыгачак, чөнки җир салкын әле. Җирдә дым бетә, дип куркырга кирәкми, бәрәңгегә беренче чиратта җылы кирәк. Тишелгәнче аның үз дымы да җитә, – диде бакчачы.

Аның әйтүенчә, 1962 елда яз нәкъ шулай иртә килгән булган.

– Безнең әти: «62 нче елда 1 майга чәчү бетте», – дип гел әйтә иде. Шуннан да иртәрәк килгәне юк әле. Тик табигать барыбер үз тәртибе белән бара. Мул уңыш алу өчен, бәрәңгене иртәрәк утыртуның бер мәгънәсе дә юк.

Ә менә җирне өч ел саен алыштырып тору бик яхшы. Безнең үзебезнең алты участок бар. Шуңа күрә бәрәңге һәрвакыт уңа. «Луговская» сорты – иң ярмалы, тәмле бәрәңге. Моннан тыш, безнең як өчен «Рамона», «Розара», «Невский» сортлары яхшы.

Тукай районының Иске Җирекле авылы фермеры Минталип Миңнеханов әйтүенчә, элита дигән репродукция алганда, бәрәңгене – 4, беренче репродукциядәгене 2-3 елдан соң алыштырып торырга кирәк. Бәрәңге сортын алыштырырга теләгән авыл халкы өчен аны табу артык авырлык тудырмый гадәттә. Мондый чакта күрше-күлән, туган-тумача ярдәмгә килә. Тик, фермер әйтүенчә, бәрәңгенең сортын белеп, тикшереп кенә утыртырга кирәк.

– Кайвакыт кеше тегеннән-моннан җыеп, нәрсә чәчкәнен дә белми. Аннан әллә ни уңыш алып булмый. Авылларда халык, гадәттә, эресен үзе ашый да, ваграк бәрәңгене утыртырга дип калдыра. Иң яхшысы 50–55 мм диаметрдагы (5,5 сантиметрга кадәрге) бәрәңге утырту. Эрене кисеп утырту да әйбәт түгел. Дөрес, булмаганда ярап тора ул, тик мин алай эшләргә киңәш итмәс идем. Чөнки киселгән бәрәңгене бактерияләр үз итә, – диде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Яңарталар һәм төзекләндерәләр

Парк-скверлар, яр буйлары һәм ишегалларын яңарту өчен тавыш бирү башлана. Республика халкы 15 апрельдән 31 майга кадәр киләсе елда төзекләндереләчәк парк-сквер, яр буйлары, ишегалларын сайлаячак. Быел тавыш бирүгә Татарстанның 45 районындагы 267 җәмәгать урыны тәкъдим ителгән.

Тавыш бирү Татарстан Дәүләт хезмәтләре сайты һәм кушымтасында, шулай ук gorodsreda.tatar.ru порталында барачак. Анда 14 яшькә җиткән барча кеше катнаша ала.

Моннан тыш, киләсе елда Татарстан Рәисенең «Безнең ишегалды» программасы буенча яңарту өчен 200 ишегалдын билгеләргә мөмкин. Быел исемлеккә 32 районнан 2145 ишегалды кергән.

Тәртибе билгеле

21 апрельдә мөселманнар Ураза гаетен бәйрәм итәчәк. Татарстан мәчетләрендә аны уздыру тәртибе билгеле булды. Быел ул изге җомга көненә туры килә.

Республика Диния нәзарәте хәбәр иткәнчә, гает бәйрәме Татарстанның шәһәр мәчетләрендә 6.30 сәгатьтә Коръән аятьләрен укып башланачак һәм 7.00 сәгатьтә гает вәгазьләре белән дәвам итәчәк. Гает намазы исә 7.30 сәгатьтә укылачак.

Авылларда гает намазын кояш чыгып ярты сәгать узгач укырга киңәш ителә.

Сүз уңаеннан, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның бәйрәм вәгазе турыдан-туры эфирда «Хозур ТВ» телеканалында, шулай ук «ТНВ-Татарстан» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында күрсәтеләчәк. Моннан тыш, гает бәйрәмен интернетта да карап була (Татарстан мөфтияте сайты, «Хозур ТВ» YouTuBe-каналы).

Көйсез апрель

Шушы көннәрдә Татарстанда һава торышы үзгәрер дип көтелә. Республикага Төньяк диңгезләр акваториясеннән салкын һава керә. Бу хакта КФУның Метеорология кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев хәбәр итте.

Аның сүзләренчә, арктик һава салкын җил өчен бөтен шартларны тудыра. Югары атмосфера басымы исә явым-төшемнәрсез һава торышын билгеләячәк.

Галим әйтүенчә, температура буенча караганда, апрельнең беренче ике атнасы майның беренче көннәренә охшаш иде. Бу чорда температура +3 градус тәшкил итә (норма – 8,5 градус).

Яңа атна башында температура норма күрсәткечләренә якынаер дип көтелә. Республика төньяк антициклон хөкемендә булачак.

Тимур Әүхәдиев фаразлавынча, киләсе ике көндә төнге температура 0 градус, көндезге температура 6–10 градус булачак. Әмма җил көчле булганлыктан, салкын булып тоелачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Имин тизлек

Хәерле булсын юллар!

Татарстанда үлем-китем белән тәмамланган юл һәлакәтләре саны кимегән. Өч айда республика юлларында 50 кешенең гомере өзелгән. Узган ел куркыныч сан 20гә күбрәк булган. Аның каравы балалар катнашындагы юл һәлакәтләре саны арткан. Юл сагында торучылар ата-аналарны, балаларны да юлларда уяу булырга чакыра.

Бу хакта Татарстан Хөкүмәтенең Юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясе утырышында Дәүләт автоинспекциясе башлыгы Рөстәм Гарипов җиткерде.

Өй айда республикада 637 юл фаҗигасе теркәлгән. Аларда 814 кеше имгәнгән. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, саннар шул килеш калган. Аның каравы һәлак булучылар 20гә кимегән.

Ел башыннан бирле Татарстан юлларында балалар катнашында 69 һәлакәт теркәлгән. Бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 6 очракка күбрәк. Быел юлларда 3 баланың гомере өзелгән, 74 бала имгәнгән. 69 юл һәлакәтенең 41ендә балалар пассажир булган.

– Тагын бер кат искәртәм. Машинага бала утырткансың икән, юл кагыйдәләрен төгәл үтәргә, икеләтә игътибарлы булырга кирәк, – ди Рөстәм Гарипов.

Ел башыннан бирле Татарстанда җәяүле балалар катнашында 27 юл һәлакәте булган. Тугыз очрак үсмерләрнең үз гаебе белән – юлларда игътибарсыз булулары аркасында килеп чыккан. Рөстәм Гарипов сүзләренә караганда, җәяүле балалар катнашындагы мондый аянычлы очракларны кисәтү максатыннан республикада даими рәвештә профилактик чаралар уздырыла.

Куркыныч санның кимүе каршы як полосага чыгу аркасында булган юл фаҗигаләре азаюга да бәйле. Андый очраклар 40 процентка кимегән. Шулай итеп, мондый аварияләрдә һәлак булучылар – 28, җәрәхәтләнүчеләр 47 процентка кимегән.

Утырышта игътибарны җәлеп иткән тагын берничә сан җиткерделәр. Татарстанда өч айда рульгә исерек килеш утырган 3283 кеше тотылган. Шуларның 311е икенче мәртәбә эләккән. Быел республикада андыйлар катнашында 25 авария килеп чыккан. Ә бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 35 процентка азрак. Аларда ике кешенең гомере өзелгән, 33 кеше имгәнгән.

Ә кагыйдә бозган кешегә җаваплылыктан котылу тагын да кыенрак булачак. Татарстанда андыйларны квадрокоптерлар ярдәмендә ачыклый башламакчылар. Бу проект Иннополис хезмәткәрләре белән берлектә тормышка ашырылачак. Квадрокоптерларны хәзерге вакытта гамәлдә булган кагыйдә бозуларны теркәү технологиясе нигезендә кулланмакчылар. Шуңа күрә кисәтү өчен махсус юл билгеләре куелмаячак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САН

Татарстанда республикалар карамагындагы юлларда 78 мең кв. м мәйданда чокыр-чакырларны төзекләндергәннәр. Федераль юлларда – 9,3 мең кв. м, Казанда – 18,5 мең, башка район һәм шәһәрләрдә исә 3,9 мең кв. м мәйданда эш башкарылган.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Илсур МЕТШИН, Казан шәһәре мэры:

Дәваларга түгел, булдырмый калырга өйрәнергә кирәк. Наркомания – бик авыр тема һәм, кызганыч ки, иң кадерле кешеләргә: балаларга, яшьләргә тия. Бу бер якка алынган билет кебек. Күп очракта аннан кайтыр юллар юк.

(Казан шәһәр Думасының XXII сессиясендә әйткән сүзләре)

ИҢ МӨҺИМ БӘЙРӘМНӘР

«Россиядәге кайсы бәйрәмне иң мөһиме дип саныйсыз?» Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре илдә яшәүчеләрдән шул хакта сорашкан.

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–20 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны	Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен** гадәти бәясе – ~~512 сум 70~~ тиен
П2409 атнага дүрт тапкыр чыга	Ташламалы бәя **1051 сум 80 тиен** гадәти бәясе – ~~1227 сум~~ 30 тиен

Реклама 16+

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тукай, мәңгелек һәм без

Татарны ничә дистә еллар күтәреп торган, затлы милләтләр арасында тоткан бөек шагыйребез Тукайның вафатына, аның җаны гарешкә ашканга иртәгә 110 ел тула. «Очты дөнья читлегеннән, тарсынып, күңелем кошы». Егерме җидесе дә тулмаган һәм инде беркайчан да тулмаячак Тукай һәм бөек мәгънәгә ия тирән фәлсәфи шигъри юллар.

Адәми зат билгесезлектән фани дөньяга килә дә тагын да шул билгесезлеккә карап китеп бара. Аның гомере – иксез-чиксез вакыт тасмасында кыска бер кисемтә генә. Кемдер шул кыска аралыкта да балкып, нур чәчеп кала, күпләр исә «Китмәскә килгән кебек яши дә, гел яшәмәгән төсле китеп тә бара». Соңгылар күп, аларның исеме – гавам. Балкыш тудыра алганнар – коточкыч дәрәҗәдә аз. Нәкъ шушы хәл җиһанны шыксыз, затсыз гына түгел, хәтта ки акылсыз итми микән? Шопенгауэр кебек мәшһүрләр тикмәгә генә: «Наш мир – наихудший из миров», – дияргә яратмаган бит. Пропорцияне азга гына үзгәртә алганда, кешелек күптән инде алтын гасырда яшәр иде. Тик биология, генетика дигәндә генә түгел, тәрбия мәсьәләләрендә дә адәми зат нык көчсез. Дин әһелләре, кеше заты фанилыкка сыналу өчен җибәрелгән, дияргә ярата. Бәлки, шулайдыр да. Тик абсолют күпчелекнең сынауны үтә алмасын белгәндә, ул мәшәкать нигә? Кешегә Мәңгелек дип атаган билгесезлек – бакыйлыкта ниләр барын, югын белү дә бирелмәгән. Әгәр дә ул дөнья чыннан да бар икән, анда, һичшиксез, иркенлек, хөрлек, гаделлек хөкем сөрергә тиештер. Һәрхәлдә сынауны үтә алган, дөрес яшәгән җаннар өчен. Башкача булганда, аннан нинди хаҗәт тә, нинди кирәклек?..

Тукай калдырган читлек. Фани дөнья – аңлаган кешегә, чыннан да, читлектер ул. Шәхес масштабы никадәр зуррак икән, ул читлек шулкадәр тар. Читлек – гомер чиклелеге генә түгел. Без туабыз да, кемнәрдер әллә кайчан ук язган кануннарга, нормаларга, гадәтләргә буйсынырга, шулар буенча яшәргә тиеш булабыз. Әгәр дә ки җиһан дигәнебездә гаделлек, камиллек, хөррият хөкем сөрсә, бу хәл аңлашылыр да иде. Тик менә дөнья дигәнебез бик тә гаделсез һәм без шул гаделсезлекне дәвам иттерергә тиеш булабыз. Тукай биеклегендәге фикер ияләре исә гомере буе фанилыкта яхшылык, камиллек эзләгән, шуңа өндәгән. Ләкин дөньяны үзгәртә, яхшырта, чистарта алмагач, шагыйребез кебек «үзе пычранып беткәч», дөнья дигән тар читлектән Мәңгелеккә ашкан.

Ашкан, ләкин даһиебыз фани дөньяда да үзен, исемен үлемсез итеп калдырганын аңлап киткәндер. Татар исәндә, Тукай исеме, аның сүзе, мирасы һәрдаим исән булыр, дигән өмет бар. Тукай калдырган читлекнең – ул гомер иткән дөнья, язмышның – нindилеге бүген һәр татар кешесенә билгеле. Ятимлек, кагылу-сугылулар, җәбер, якадан алган авыру, яраткан халкының авыр язмышы. Тоташ михнәтләрдән торган яшәеш. Чикләнгән кыска гомер, чикләнгән бәхет, чикләнгән йә бөтенләй булмаган рәхәтлекләр. Бөек михнәтләр кешене йә буй җитмәс биеклеккә күтәрә, йә бик түбәнгә төшерә. Тукай, дөньялыкта, аның тар читлегендә үлемсез әсәрләр тудырып, биеккә – бөеклеккә ашты. Тукай булмаса, татар бүген бер башка түбәнрәк булыр иде. Бәхетебез: Ходай безгә тулыр-тулмас 27 елга Тукайны биргән.

Без бүген дә Тукай аһәңе, аның яктысы, аның рухы белән яшибез. Яшәргә тырышабыз. Без әлегә исән. Исәнлек белән без Тукайга да бурычлы. Тик татар гомер-гомергә бер Тукайга гына сыенып исән кала алмый. Татарга Тукай биеклегенә күтәрелә алган, милләтне күтәргән башка шәхесләр дә кирәк. Бүгенге вазгыятьтә бигрәк тә. Вазгыять дигәнебез тагын шунысы белән үзенчәлекле: милләттә бүген батырлык, фидакарьлек дефициты бар, сизелә. Ялкынлы шигъри сүз дигәндә дә барысы да ал да гөл үк түгел. Ә бит яңа Тукайлар, ул үзе әйтмешли, «Коеп куйган шагыйрь генә түгел, сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә» булганнар, шагыйрьне дә уздырып, милләт дигәндә утка, суга керергә әзер затлар яралганда, балкып янганда, маяк булганда, без янә дә берничә башка югары күтәрелә алыр идек. Булырмы, килерме андый затлар, андый заманнар? Мөхәммәт Мәһдиевчә «едва ли» димәсәк тә, күңелдә тынычлык юк.

Ни кызганыч, дөнья шундыйга әйләнде, һәммә кеше анда җайлашу юлын сайлый. Җайлашу аша адәми зат үзенә уңайлык, комфорт эзли. Буйсына, принципларга уйламый да хыянәт итә, флюгер урынына җил уңаена һәрчак борылып тора. Нәтиҗәдә ихласлыкка, батырлыкка, туры сүзгә мәйдан тарая. Беренче урында – шәхси, мин-минлекле мәнфәгатьләр, мал-мөлкәт, шикле күңел ачулар. Шуларга ирешү юлында кеше заты бер дә тартынмыйча икейөзлеләнә, бер нәрсә уйлый да гел башканы сөйли. Кем әйтмешли, үзенә файда дигәндә ул эткә дә «җизни» дип дәшәргә әзер. Шунлыктанмы, дөньябыз да төрле декорацияләр, фейклар, бутафорияләр белән тулы. Булгаков персонажы әйтмешли, «нәрсәгә генә тотынма – шул юк». Ясалмалык, ялагайлык чорына кергәндә тугры Тукайлар туу ихтималы зур түгел шул.

Әгәр дә кемдер туып, (шагыйрь булу гына димәгән), дөнья рәхәтлекләренә кулын селтәп, үзен көрәшкә багышласа, милләтне күтәрүдә, аны затлы, ирекле итүдә Тукайлар, Исхакыйлар эстафетасын үзенә ала алса, милләт байрагы булып күтәрелсә, бүгенге проблемалар – телсезләнү, үзаң сайлыгын күпкә, бик күпкә киметеп булыр иде кебек. Татар зыялыларын авызына карата алырлык, югары җитәкчеләр һәр әйткән сүзенә колак салырлык Шәхесебез, кызганыч ки, күренекле саналган затларыбыз булып та, әлегә юк. Бүгенге затсыз заманда милләт байрагы булу ай-һай кыен шул ул.

Без яшәгән бүгенге дәвер, ни кызганыч, бөек идеяләр, бөек омтылышлар, бөек гамәлләр чоры түгел. Барысын да акча алыштырды. Меркантиль дөнья зур адымнар белән каядыр чаба. Чаба, ләкин үзенең кая барганын белми. Бүгенге кеше җиһанга рентабельле кечкенә предприятие булыр өчен туа. Тик барысы да, ахыр килеп, вак хаҗәтләр, вак эшләргә, идән астындагы тычкан чабышына барып тоташа. Кесәң калынмы? Автомобилең нинди? Кәнәфиең йомшакмы? Коттеджың ничә катлы? Бала-чагалык түгел бу. Балада самимилек була. Бу – шайтан котыртуы һәм шайтан әзерләгән читлек. Күпләр үзен шул читлек эченә кертә һәм шунда «рәхәт чигә». Аны һич тарсынмый. Тарсыну өчен шәхес булу кирәк ич…

Милләт дип җан атканнарны исә хәзерге чынбарлыкта, зур булмаса да, якты бер өмет яшәтә: Тукай бөеклеген таный белгәндә, аны онытмаганда, татар исән булыр, дигән өмет.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ОСТАЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР

«Кадрлар резервы» – республиканың идарә итү потенциалын үстерү максатын күздә тоткан проект. Ул 2014 елдан бирле уза. Анда катнашу өчен Татарстанның иң яхшы идарәчеләрен сайлап алалар. Ел дәвамында резервчылар республика һәм федераль белгечләрдә махсус укулар уза, республика муниципалитетларында һәм предприятиеләрендә стажировка программасында катнаша, остазлар белән берлектә Татарстанның социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән проектлар әзерли.

Тармакларны цифрлаштыру, агросәнәгать комплексын үстерү, төзелеш тармаган камилләштерү. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханновка «Кадрлар резервы» программасы катнашучылары үз проектларын тәкъдим итте. Чара Хөкүмәт йортында узды. Анда шулай ук Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов та катнашты.

Резерв вәкилләре Татарстанның социаль-икътисадый үсешенә бәйле проектларны тәкъдим итте. Проектларның күп өлеше аерым тармакларны цифрлаштыру, агросәнәгать комплексын, сәламәтлек саклау, социаль өлкәне үстерү, шул исәптән төзелеш тармагын камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Рөстәм Миңнеханов «Кадрлар резервы»нда катнашучыларның инициативаларын уңай бәяләде. Ул тиешле ведомстволарга алар тәкъдим иткән проектларга игътибар итәргә кушты.

Чистарту икеайлыгы

Җирдән булмаса, күктән табалар

Татарстанда өмәләр дәвам итә. Кар эреп, җиргә бөтен «байлык» чыга башлагач, җыештырмый кая барасың? Елдагыча, берәү ташлый, икенчеләр аның артыннан җыя. Чистарту икеайлыгы 1 апрельдә башланды.

Кукмара районының Төркәш авылында яшәүчеләр дә өмәгә чыкты. Ихаталарын чистарткач, урамнарны тәртипкә китерделәр. Әлки районынның Базарлы Матак авылында да инде зурлап өмәләр үткәрелә. Мамадыш районынның Усали авылы балалары елга буйларын, балалар мәйданчыкларын, Җиңү һәйкәлен тәртипкә китергән.

Шәһәрләр дә калышмый. «ЧИСТАБУЛАЧАК» экология хәрәкәте активистлары чистарту икеайлыгының беренче атнасында ук 16 чара уздырган. Болар барысы да тирәякны яңарту, чистартуга бәйле. Яшьләр Казансу яр буеннан ике сәгать эчендә 26 капчык чүп җыеп алган.

Әмма күпме генә җыйсаң да, чүпнең бетәсе юк кебек. Шушы көннәрдә экологлар Казан буйлап рейдка чыкты һәм тау кадәрле чүплекләргә тап булдылар.

Беренче тукталыш Мәскәү районында урнашкан Фурманов урамы иде. Биредә иске йортлар янәшәсендә чүп өеме пәйда булган. Аңлашыла инде, үзеннән-үзе барлыкка килмәгән: кемдер нидер төзегән дә төзелеш калдыкларын бушатып калдырган. Бу җирнең хуҗасы – Киров һәм Мәскәү районы хакимияте. Аларга карата беркетмә язылып, әлеге документ судка тапшырылган. Суд карары буенча әлеге чүплек юкка чыгарылырга тиеш булса да, берни үзгәрмәгән.

Гудованцев урамында төзелеш калдыкларыннан өелгән чүплекнең биеклеге 9 метрга җиткән.

– Быел март аенда бирегә чүп ташулары турында хәбәр килгән иде. Якын-тирәдә яшәүче кешеләр ярдәме белән чүп ташлаучы машинаның маркасын, номерын таптык. Машина хуҗасы җавапка тартылды. Җир хуҗасына чүплекне бетерергә кушылды, – ди Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының үзәк территориаль идарәсе баш белгече Вадим Габдуллин.

Киләсе тукталыш Мариуполь урамында иде. Биредә чүп контейнерлары тулып ташыган.

– Чүп җыючы төбәк операторлары калдыкларны вакытында алып китәргә тиеш. Район хакимияте бу урынның чисталыгы өчен җавап бирә һәм тәртиптә булуын контрольдә тота. Аларга бу хакта хат җибәрелде, – ди белгеч.

Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Илнур Гобәйдуллин чүплекләрне күктән тикшерде. Ул Казан, Кама Тамагы, Тәтеш, Буа, Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Яшел Үзән, Биектау, Питрәч, Лаеш районнары өстеннән очып, андагы чисталыкка бәя бирде. «Эш җитәрлек әле», – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Чистарту икеайлыгы башланганнан бирле экологлар табигатькә зыян салуның 793 очрагын теркәгән. Шуның 173е инде төзәтелгән. 161 кешегә беркетмә төзелгән. 113 мең сумлык штраф салынган. 369 чүплек табылып, аның 101е юкка чыгарылган. 26,9 кубометр каты көнкүреш калдыклары чыгарылган. Өмәләрдә 68 мең кеше катнашкан. 1761 агач утыртылган.

Спорт кына түгел бу

Гасырлык хәрәкәт

Июньдә Казанда тагын бер зур спорт чарасы көтелә. «Динамо» спорт уеннарына физик культура һәм спорт җәмгыятенең 76 төбәктәге оешмалары һәм 4 илдән спортчылары – барлыгы 2,5 мең кеше җыелачак. Әлеге спорт бәйрәме җәмгыятьнең 100 еллык юбилеена багышлана.

Татарстандагы «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте рәисенең беренче урынбасары Салават Гайсин әйтүенчә, ярышлар 11 төр буенча узачак. 15–21 июнь көннәрендә Казанда пистолет һәм автоматтан ату, җиңел атлетика, самбо, йөзү, мини-футбол, волейбол һәм спорт төрләрендәге осталар үз көчен күрсәтәчәк.

«Динамо»ның юбилее исә киләсе атнада – 18 апрельдә билгеләп үтелә. Мәскәүдә узасы тантанага Татарстан вәкилләре дә бара. 12 июнь – Россия көнендә Казанда да юбилей уңаеннан чаралар көтелә. Аңа кадәр Татарстан башкаласында кинофестиваль узачак. «Динамо ул – профессиональ спортчылар гына түгел. Әлеге җәмгыять ветераннарны да, балалар спорт мәктәпләрен дә, хәйриячелек хәркәтен, башка юнәлешләрне дә колачлый. Шуңа күрә безгә тарихны сакларга, традицияләрнең кадерен белергә кирәк», – ди Россиянең атказанган тренеры, «Бердәм Россия» партиясенең «Балалар спорты» һәм «Чиксез спорт» проектлары төбәк координаторы Ольга Павлова.

ИРТӘ КИРӘКМИ КӨТӘРГӘ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Орлыклык бәрәңгене исә Түбән Кама районының Смыловка авылы фермеры Владимир Аппаковтан, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Нәсим Дәүләтовтан алырга мөмкин. Сүз уңаеннан, Казандагы кибетләрдә «Скарлет элита» сортлы ике килограмм чәчүлек бәрәңге 333 сумга сатыла.

Авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Фәния Җамалиева фикеренчә, туфракта 8 градус җылылык икән, бәрәңгене утыртырга вакыт җиткән дигән сүз.

– Гадәттә, безнең якларда аны майның 10–20ләре тирәсендә утырталар. Быел да шулай булыр, – ди ул. – Уңышның нигезе – орлыкта. Гел бер туфракта үскән бәрәңгедә төрле авырулар туплана, нәтиҗәдә ул начар үсә башлый. Ләкин орлыклык бәрәңгене дә теләсә каян алырга ярамый. Бары орлык сату буенча махсуслашкан кибетләрдән генә алырга мөмкин. Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында да безнең яклар өчен яраклашкан җиде төрле сорт сатыла.

Галимә, сортларны алмаштырырга уйлаганда, көздән аяк киенеп куярга куша. Бер бакчага берничә төрле бәрәңге утыртырга киңәш итә. Чөнки уңыш елның ничек килүенә бәйле.

– Хәзер сортлар бик күп. Бер үк җирдә үскән «Удача», «Невский» сортлары бик тиз зарарлана, авыруларга бирешә, – диде ул. – «Рокко» чыдамрак. Тәмгә уртача. Уңышы да әйбәт, коры черек авыруына да бирешми. Соңгы вакытта шәхси хуҗалыкларга әлеге сортны утыртырга киңәш итә башладык.

КЕЧКЕНӘ ДӘ ТҮЗ ГЕНӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Төзелеш

Татарстанда яңа төзелүче йортларның 74 проценты сатылмаган. Әлеге күрсәткеч буенча илкүләм саннарны да узып киткәнбез хәтта. Моның сәбәпләре дә аңлашыла кебек: бер яктан, республикада торак бәясе «тешләсә», икенче яктан, бүген халыкта фатир сату-алу кайгысы юк. Бездә генә түгел, ил күләмендә дә шул ук хәл. Торак базарын коткару өчен, яңа ташламалар турында да сөйләшә башладылар инде. Фатир бәяләре төшәрме?

Казанда яшәүче Хәкимуллиннар Универсиада проспектындагы ике бүлмәле фатирларын өчлегә алмаштырмакчы.

– Интернетка игъланны Яңа ел бәйрәмнәрендә үк куйган идек. Өч ай эчендә фатирны карарга биш-алты кеше килде. Әле алары да тәгаен: «Алабыз!» – диючеләр түгел. Фатирларны карап, бәяләрне чагыштырып кына йөриләр. Торакны сатам дисәң дә, алучысы юк хәзер, – ди гаилә башлыгы Дамир Хәкимуллин.

Аның сүзләрен риелтор Сания Мусина да куәтли.

– Сату-алулар саны икеләтә диярлек кимеде. Халыкта акча юк, фатир кайгысы да түгел. Икенчел торак базарында ипотека ставкасы югары – 11 процент чамасы. Түли-түли, фатирың ат бәясенә төшәчәк. Шуңа күрә кулында азмы-күпме акчасы булганнар яңа йорттан фатир сатып алырга тырыша. Чөнки беренчел торак базарында ташламалы ипотека гамәлдә. Тик яңа йортларда да бәяләр чүпрә салган кебек бик тиз үсә. Халык булган акчасын әрәм-шәрәм итмичә, аны җыеп барырга кереште, – ди ул.

Илнең төзелеш һәм ТКХ министры Ирек Фәйзуллин сүзләренә караганда, бүген яңа торак базарында фатирларның 80 проценты ташламалы ипотека дәүләт программалары ярдәмендә сатыла. Һәр ун фатирның сигезе дигән сүз бу! Быел гыйнвардан гаилә ипотекасына үзгәрешләр дә керде. Хәзер аны 18 яше тулмаган ике бала тәрбияләүче гаиләләр алырга хокуклы. Моңарчы гаилә ипотекасын 2018 елдан соң икенче һәм аннан соңгы бәбиен алып кайтучыларга гына бирәләр иде. Ипотека ставкасы шул ук – 6 процент. 2024 елның 1 июленә кадәр озайтылган ташламалы ипотека буенча ипотека ставкасы исә 8 процент тәшкил итә.

Моңа да кызыкмыйлар. Соңгы мәгълүматларга караганда, ил күләмендә яңа фатирларның 69 проценты сатылмый. Ә Татарстанда әлеге күрсәткеч 74 процент тәшкил итә. Соңгы ике елда республикада хуҗасыз яңа фатирлар саны ике тапкыр арткан. Дөрес, елдан-ел күбрәк тә төзибез.

– Былтыр республикада 3 миллион 93 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылган. Бу – рекордлы сан! Әлеге күрсәткеч буенча без Идел буе федераль округында – беренче, ил күләмендә – алтынчы урында, – дип сөйләде еллык коллегия утырышында Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин.

Төзүчеләргә эшне киметергә дә җыенмыйлар. Ник дисәң, Россия Президенты карары нигезендә 2030 елда илдә елына 120 миллион квадрат метр торак кулланышка тапшырылырга тиеш (былтыр ул 102,7 миллион квадрат метр тәшкил иткән. – **Ред.**). Ә моның өчен төбәкләр елдан-ел тырышыбрак эшләргә тиеш, билгеле. Бу хакта безнекеләргә Төзелеш министрлыгының коллегия утырышында катнашкан Россия төзелеш һәм ТКХ министры урынбасары Никита Стасишин да искәртте. Эш шунда ки, быел тармакта ким дигәндә 2 миллион 830 мең квадрат метр торак кулланышка тапшыру күздә тотыла. «Мин Татарстанда бу күрсәткеч быел да 3 миллионнан артып китәр дип уйлыйм, чөнки күрше Башкортстанда 3 миллион квадрат метр чамасы торак төзергә ниятлиләр», – диде Мәскәү кунагы, уенын-чынын бергә кушып.

Былтыр Татарстанда 105 мең гаилә торак шартларын яхшырткан. Дөрес, белгечләр фаразлавы буенча, әлеге сан 113 меңне тәшкил итәргә тиеш булган. Халыкның кесә ягы такыраюны исәпкә алмаганнар, күрәсең. «Дом.РФ» мәгълүматларына караганда, Казанда яңа фатирның бер квадрат метры уртача 165 мең сум тәшкил итә. Әлеге күрсәткеч буенча без ил күләмендә беренче бишлеккә керәбез. Моның нәтиҗәсе буларак, былтыр республикада ипотека рәсмиләштерүчеләр саны 34 процентка кимегән әнә.

Эшнең кая таба барганын аңлап, Россия төзелеш һәм ТКХ министры Ирек Фәйзуллин төзелеш оешмаларына яңа торакның бер квадрат метры бәясен төшерергә дә тәкъдим итте. «Моның өчен мөмкинлекләр бар», – диде ул. Министр белми әйтмәс. Илкүләм Инженерлар-смета төзүчеләр берлеге китергән саннарга ышансаң, Казанда, мәсәлән, торак төзелешенең үзкыйммәте аның базар бәясеннән ике тапкыр (!) арзанрак. Җир рәсмиләштерү, төзелеш эшләре, инженер челтәрләренә тоташтыру, төзекләндерү кебек эшләрне исәпкә алып, республика башкаласында яңа йорт салуның бер квадрат метры 82 мең сумга төшә, ди белгечләр. Без – бәя өстәү буенча да Идел буе федераль округында беренче урында.

– Тик бер күтәргән бәяне кире төшерүләре бик шикле, – ди башкаладагы милек агентлыгы җитәкчесе Мария Николаева. – Торак бәясе якын арада артмаячак. Мин менә шуңа күбрәк ышанам. Төзүчеләр фатир сатып алучыларга бушлай машина кую, коридорда әйберләр саклау урыны тәкъдим итү, балконны ремонтлап бирү кебек «бонус»лар белән кызыктыра башларга мөмкин. Бераз көтик.

Ул арада Россия Президенты Владимир Путин торак шартларын яхшыртырга теләүчеләргә өстәмә ташламалар булдырырга киңәш итте. Бүген илдә төзелүче һәр ике фатирның берсе бер бүлмәле яки «студия» икән. Кем әйтмешли, соравына күрә – тәкъдиме. Гаиләләрне иркенрәк тормышта яшәргә этәрү өчен, алга таба фатир зуррак мәйданлы булган саен, аңа ипотека ставкасын төшерергә мөмкиннәр. Илбашы ташламалы ипотеканы икенчел торак базарына да гамәлгә кертергә тәкъдим итте. Моннан өч ел элек дәүләт ярдәме гамәлгә кергәннән соң, беренчел торак базарында бәяләрнең уртача 80 процентка артуын исәпкә алсаң, бүген арзанрак саналган иске фатир бәяләре дә күккә сикермәгәе. Без әйтмәдек, Путин әйтте!

Эльвира ВӘЛИЕВА

МӘҢГЕЛЕККӘ ЮЛ

Хәтер-хатирә

Быел Тукаебызның бакыйлыкка күчкәненә – 110 ел. Гомере 27 яше дә тулмыйча өзелгән, иҗат гомере дә кыска булган бөек шагыйребез безгә бәяләп бетермәслек әдәби мирас бүләк итеп калдырган. Милләтебезнең киләчәккә барыр юлын да сызган. Тукай юлы – татар өчен мәңгелек юл. Тукай рухы һәр татар күңелендә яшәсә, милләт тә озын гомерле булачак.

Еллар узган саен хәтер дә әкренләп юылырга мөмкин, шуңа күрә без аны һаман яңартып торырга тиеш. Бүген исә аның вафат булган көнендә, Тукайны мәңгелеккә илткән юлның соңгы чакрымнарын, шагыйрь гомеренең соңгы мизгелләрен күңелдә тагын бер кат барлыйсы, яңартасы килә.

1913 елның 17 нче апрель (иске стиль буенча 4 нче апрель) көне. Казанның үзәк Проломный урамы буйлап Клячкин шифаханәсе ягына халык агыла. Төш турысы җиткәч, больница капкасыннан чәчәккә күмелгән мәрхүмне алып чыгалар. Шәһәрнең Яңа бистә зиратында бөек шагыйрьнең мәете кабергә иңдерелә. Габдулла Тукайның үлемсезлеккә, мәңгелеккә илтүче соңгы юлы әнә шулай тәмамлана. Казан каласының моңа кадәр шул дәрәҗәдә күп халык җыйган җеназа күргәне булмый. Меңләгән кеше сөекле шагыйрен озатырга килә. Бу көнне газета, журналларда Тукайга багышланган мәкалә, истәлекләр, шигырь, бәетләр бастырыла. Нәшриятлар, китап кибетләре, редакцияләр ябыла. Мәдрәсәләрдә укулар туктатыла. Рәсәйнең төрле почмакларыннан кайгы телеграммалары агыла.

1913 елның 15 апрелендә (иске стиль буенча 2 апрель) Габдулла Тукайның гомере үпкә чиреннән өзелә. Туберкулезның беренче билгеләре Тукайны 1910 елда борчый башлый. 1911 елның май аенда, ул табиб һәм җәмәгать эшлеклесе Нариман Нариманов киңәше буенча, Әстерханда кымыз эчеп, бераз сәламәтлеген яхшырта. Көз җитә. Тукай, яшәгән кунакханә бинасы тиешенчә җылытылмый. «Миңа шул якмый торган арада бизгәкнең шәбе эләккән. Шуңа күрә, мин, җылылык-фәлән сизмичә, көне-төне туңуда идем», – дип искә ала ул үзе. Кунакханәнең салкынлыгына түзә алмыйча, Тукай декабрь башында ямщик яллап, Өчилегә юл тота. Туганы Кәшфелкәбирнең тормыш иптәше, Тукайның җиңгәсе Рәбига Әмирова истәлекләрендә мондый сүзләр бар: «Ул чанада толыпка төренеп яткан иде. Аягында – чуар киез итек. Чанадан үзе төшә алмады, ирем белән без култыклап төшереп, күтәреп өйгә алып кердек. Гәүдә бик кечкенә булганга, ябыкканга күрә күтәрергә бик җиңел иде. Үзенең әйберсе дә, акчасы да юк иде. Без аны башта үзебез тора торган өйгә генә урнаштырдык. Ул вакытта кышын ягылмый торган кечкенә бер өебез бар иде. Ул кайткач, җылытып, Габдулланы шунда күчереп урнаштырдык. Берәр атнага кадәр урыныннан кузгала алмады… Үзенең рухы бик төшенке, бер дә рәтләп сөйләшми иде. Мин ашарга хәзерләп кертәм, ирем ашата иде… Ул миңа бик рәхмәтләр укый иде. Шул вакытта абыйсына: «Кашки минем сабый вакытымда да шул җиңги булган булса икән», – дип сөйләгән».

Яз җитүгә, янәдән көч җыеп, калага кайта Тукай. 1912 елның апрелендә Петербург университеты студентларына лекция укыган вакытта, шагыйрьнең хәле кинәт начарлана. Авыруны университет профессоры, табиб Александр Поль бик җентекләп караганнан соң төгәл диагноз куя. Тукайның замандашы, юрист, педагог Шакир Мөхәммәдъяровка бу хакта хәбәр итә. Хәле авыр булуын искәртеп, бер як үпкәсенең бөтенләй эштән чыкканлыгын, икенче үпкәнең дә яртысы гына сау булуын аңлата. Кичекмәстән хастаханәгә ятарга тәкъдим итә. Габдулла Тукай ризасызлыгын белдереп: «Без больницаны үлемнең әүвәлге стансасы дип беләмез. Аз булса да дөньяда торып калыйм», – дип җавап бирә. Дуслары киңәше буенча Троицк шәһәрендә кымыз белән дәваланганнан соң, янәдән Казанга кайта. Ләкин авыру бик тиз аза, шагыйрьне бернәрсә дә коткара алмый. 1913 елның февраль аенда, Тукай Клячкин клиникасына керер алдыннан дусты Фатих Әмирханның: «Тиз терелеп чык, тиз күрешик!» – дигән сүзләренә «Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә!» – дип җавап бирә. Шагыйрь гомеренең инде санаулы гына көннәре калганын сизенә. Шуңа күрә бер генә көнен дә әрәм итми, халыкка әйтәсе сүзләрен әйтеп калдырырга ашыга. Соңгы минутларына кадәр үзен иҗатка багышлый.

Тукай – чын мәгънәсендә милләтпәрвәр, халык язмышы өчен янып яшәгән шәхес. Тукай кабызган шигърият учагы гасырдан артык безнең күңелләребезне кояштай җылыта! Якташыбыз шагыйрь Наил Касыймов Тукай язмышының асылын шушы дүрт юлга сыйдырып бетерә алган кебек:

Ятимлеге аның – язмыштандыр,
Бөеклеге ләкин – халыктан!
Тукай үзе халкын үксезлектән
Йолып алыр өчен калыккан!

Руфия ХӨРМӘТОВА,
Тукай-Кырлай музее хезмәткәре

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар

КАДЕРЕН БЕЛИК

Кем белер кадереңне, иркәм,
Яныңда былбыл булмаса?
Габдулла ТУКАЙ

Язманы Тукайның әлеге шигырь юллары белән башлавым очраклы түгел. Миңа калса, ул – тау кадәрле эшләр башкарып та, күләгәдә калган шәхесләрнең берсе. Ул инде күптән Тукай премиясенә лаек. Сүзем – музыка белгече Земфира Сәйдәшева хакында.

Иң элек Земфира Нурмөхәммәт кызының авыр балачагы турында искәртеп үтик. Кызганыч, 1937 нче еллар фаҗигасе аларның гаиләсенә дә кагыла, аның әтисен шушы ел азагында, Яңа ел бәйрәменә санаулы гына калган көннәрдә кулга алалар. Әнисе, ике улы һәм бер кызын кочып, Земфира белән йөкле килеш ялгыз кала. Әтиләре шул киткәннән әйләнеп кайтмый, исеме исә Сталин чоры үткәннән соң гына аклана. Мөгаен, авыр тормыш Земфираны чыныктырган, холкын ныгыткан, гадел булырга өйрәткәндер дә. Хәер, әтисе Нурмөхәммәт шушы сыйфатлары өчен харап булгандыр да…

Татарстан музыка белгечләре арасында Земфира Нурмөхәммәтовна алдынгы урыннарның берсен алып тора. Аның татар музыкасы проблемаларына бәйле беренче язмалары Казан консерваториясендә укыганда ук басыла. Соңрак ул бу өлкәдәге үз эшчәнлеген педагог буларак дәвам итә. Укыткан елларда студентларның фольклор-этнографик практикасын башлап җибәрә. Татарстан районнарына ел саен экспедицияләргә чыгалар, нәтиҗәдә педагог җыелган материалны нотага транскрипцияләү буенча дәресләр оештыра. Татарларның озын җырларын өйрәнү буенча да ул зур эш башкара. Аның әлеге методик эшләнмәләрнең беренче нәтиҗәләре 1977 елда ук «Совет музыкасы» журналында «Мелодика и нотация» мәкаләсендә басыла.

Ә инде сиксәненче елларның икенче яртысында, илдәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Казан консерваториясендә татар фольклоры буенча да мөстәкыйль курс кертү мөмкинлеге барлыкка килгәч, ул бу юнәлешне үз өстенә ала. Соңрак рус һәм татар фольклоры буенча курслар кушылып, «Музыкаль этнография» буларак укытыла башлый.

2007 елда Татарстанның музыка вузлары өчен аның «Татар музыка этнографиясе» дәреслеге дөнья күрә, тагын бер елдан «Татар музыкасы: тарих һәм заманчалык» исемле мәкаләләр җыентыгы басылып чыга.

Инде Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы мохиткә дә тукталыйк. Әйтергә кирәк, аңа бу уку йортындагы мохит студентларга белем бирү генә түгел, фән белән шөгыльләнүгә дә этәргеч бирә. Гәрчә ул гомере буе укытучы булып кына да эшли алыр иде. Менә мин югары белем алгач, үсешемдә туктап калдым. Фән кешеләре белән аралашып яшәсәм дә, «Композитор Мансур Мозаффаров» дигән кандидатлык диссертациясен язсам да, фәнгә кереп китмәдем. Лекторлык эше алып бардым, журналистика белән шөгыльләндем, үземнең нәни генә уңышларыма да сөенеп яшәдем. Югары материяләр турында уйларга җөрьәт итмичә, тыныч кына пропаганда эшен алып бардым. Яшьтәшем исә әнә шундый биеклекләргә күтәрелде! Аның фәнни эзләнүләренең һәр этабы китап чыгару белән төгәлләнә. Дистәгә якын китап авторы инде ул. Китап язу эшенә исә Тел, әдәбият һәм тарих институтында Ярми, Надиров кебек галимнәр арасында эшләгәндә өйрәнә.

Әйткәнемчә, Земфира Сәйдәшева – үз гомерендә бик күп кыенлыклар, үпкә-рәнҗешләр кичергән кеше. Әмма язмыш аны сындырмаган, ә чыныктырган гына. Репрессияләнгән кешенең кызы буларак консерваториягә дә беренче омтылышта ук керә алмаган. Юллама буенча Бөгелмә шәһәренә музыка мәктәбенә эшләргә җибәрелгән. Тел, әдәбият һәм тарих институтында, шулай ук консерваториядә дә барысы да шома гына бармаган… Хәтта, янәсе, һөнәренә туры килми, диючеләр дә булган. Кыскасы, барысын да – утны да, суны да кичкән.

Әмма ул бернигә карамыйча тыныч кына эшләвен дәвам иттерде. 1998 ел азагында Мәскәүдә докторлык диссертациясен яклады. Беренче милли диссертация бу. Кыскасы, аның түземлеге, ныклыгы белән горурланырга гына кала.

Галимәнең ике баласы бар. Улы – фәннәр кандидаты, ТИСБИда кафедра мөдире, әйдәп баручы белгеч. Кызы – югары белемле икътисадчы. Дүрт оныгына чиксез сөенеп яши ул.

Көн кадагындагы мәкаләләренең матбугатта даими рәвештә басылып торуын да әйтеп үтәргә кирәк. Шулай ук бөтен ил күләмендә төрле фәнни конференцияләрдә дә чыгыш ясый әле ул. Әйдәп баручы белгеч, музыка белгече буларак, башка вузлар үзләренә чакырып тора. Әйтик, Баку консерваториясендә этномузыкология курсы буенча лекцияләр укый.

Земфира Сәйдәшева – республиканың югары премиясенә тәкъдим итүгә бик лаеклы шәхес.

Клара ТАҖИЕВА

Наил Галиуллинның шәхси архивыннан

Соклану

Игелек һәм рәхмәт иясе

Һәр авылда бер Наил булсамы? Йортлар төзек, нигезләр нык, зиратлар чистартылган, мәчет ишеге ачык, урам тулы бала-чага булыр иде. Апас районының Коштавылы авылында боларның барысы да бар.

Читтәге якташлары, авыл бетмәсен, яшьләр читкә китмәсен өчен, кулдан килгәннең барысын да эшли. Әле җырчылар чакырып, концерт бүләк итәләр, әле балалар өчен цирк килә. Баларны да Казандагы «Апас» якташлык җәмгыяте оештыра.

Бу оешмага быел 30 ел тула. Авыл белән шәһәр арасын әнә шушы вакыт эчендә якынайтып, җылытып яши алар. Авылдагыларны да сөендерәләр, шәһәрдәге якташларын да онытмыйлар. Бәйрәмнәрдә очрашып торалар. Күптән түгел җәмгыятьнең вице-президенты Наил Галиуллин якташларын зур матур чарага җыйды. Ураза аена туры килгәнлектән, әлеге бәйрәм өч чараны үз эченә алган иде. Беренчесе – якташлар очрашуы, икенчесе – ифтар мәҗлесе, өченчесе – Наил Галиуллинның юбилее. Ә кунакларның барысы да – апасныкылар. Әлеге гамәле белән ул тагын бер кат якташларын хөрмәт итүен күрсәтте.

– Наил кебекләр башка юк ул. Юк, дип әйтә белми. Нинди генә ярдәм сорама, хәл итәргә тырыша, – ди якташы Алсу Бикбаева. – Безне берләштереп, бер учка җыеп, бәйрәмнәрдә хәл белешеп, онытмауларына зур рәхмәт.

Апаслыларның эшчәнлеге республикадагы якташлар җәмгыятьләре арасында югары бәяләнә. Алар ел саен төрле бәйгеләрдә катнаша. Әлегә өченче, икенче урыннар яулап килделәр. Быел исә исәпләре зурдан – беренче булмакчылар. Беренче дигәннән, алар – үз авыллары турында иң күп китап чыгаручылар да.

– Бездә ундүрт авылның китабы бар. Беренчесен моннан 15 ел элек Марат Нуриев үз авылы турында чыгарган иде. Якташлык җәмгыятендәгеләр, шулай бер-берсеннән күреп, китаплар чыгардылар. Мәчетләребез турындагылары да бар. Бер карасаң, гади генә эш кебек. Әмма китапка салынган истәлекләр югалмый. Яшь буынга без үз тарихыбызны алар аша тапшырабыз. Нинди генә эш булмасын, бик теләп катнашам, – ди Наил Галиуллин.

Килгән кунаклар аның артык тыйнак булуын да билгеләп үтте. Катнашу бер хәл, үзеңнән саллы ярдәм күрсәтү – бөтенләй башка нәрсә. Хәләл акчаңны бүлешә белү дә кирәк. Якташлары аны киң күңелле, ярдәмчел булганы өчен хөрмәт итә. Һәр котлаган кеше сүзен рәхмәттән башлады. Яшьрәк якташлары аны үзебезгә үрнәк итеп куябыз, диләр. Барысының да Наил абыйлары кебек буласы килә.

– Наил кечкенәдән ярдәмчел булды. Аның йөрәгенә кешеләргә булышу сыйфаты әллә кайчан кереп урнашкан иде инде. Ул – авылның иң уңган, иң булган гаиләсендә туып үскән кеше. Авыл дип яши, безне дә үзенә иярттә алды, – ди Россиянең атказанган табибы Рәшит Байбиков.

Татарстанның халык артисты Фердинант Сәлахов та юбилярның тыйнаклыгын билгеләп үтте.

– Ул беркайчан да үз эшен күрсәтми, аны күпертми. Кешеләр күрсеннәр, дип тырышмый да. Аның җан таләбе шундый. Яшәү рәвеше шундый, – ди ул.

Яшәү рәвеше дигәннән, бу чара аның бар дөньясына тәңгәл килә иде. Дөрес юлдан атлаган, дин тоткан, кешеләргә игелек кылган кешенең бәйрәмен башкача үткәреп тә булмас иде. Әнә нинди матур гаиләнең башлыгы ул. Янәшәсендә Зөбәрҗәте елмаеп кына тора. «Син мине рәхәт яшәттең», – диюенә күпме сер сыйган! Улларының хаҗ сәфәренә юллама бүләк итүе, киленнәренең: «Әти! Без сезне яратабыз, рәхмәт», – диюе дә зур бәя бит. Нинди генә эшкә тотынсаң да, ышанычлы тыл, тугры дуслар, якын иткән туганнарың кирәк. Ә алар Наил абыйда җитәрлек.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык өченче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык өченче утырышын 2023 елның 20 апрелендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Рәисе вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре, 2023 елның 13 апреле. № 1928-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык өченче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык өченче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. 2022 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап.
3. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 397-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
4. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 409-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 417-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 414-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 416-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 413-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 415-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.
11. «2022 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы доклады.
12. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның апреленә кадәрге эш чоры өчен хисабы.
13. «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законның 3 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 310910-8 номерлы федераль закон проекты турында (конгресс-күргәзмә эшчәнлегенең хокукый нигезләрен беркетү өлешендә).
14. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 306906-8 номерлы федераль закон проекты хакында (экскурсоводлар (гидлар), тәрҗемәче гидлар һәм (яисә) озатучы инструкторлар эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметын билгеләү өлешендә).
15. «Россия Федерациясе Торак кодексының 199 статьясына үзгәреш кертү турында» 321568-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йортлар белән даими идарә итү өлешендә).
16. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 304096-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдалану өлешендә).
17. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 322234-8 номерлы федераль закон проекты хакында (торак пунктлар чикләрен һәм территориаль зоналар чикләрен билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне җайга салу максатларында).
18. Күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Мурманск өлкә Думасы мөрәҗәгате хакында.
19. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 295373-8 номерлы федераль закон проекты хакында (хайваннарны яклаучылар эшчәнлеген җайга салу өлешендә).
20. «Россия Федерациясендә тынлыкны һәм граждан нар тынычлыгын саклау турында» 299053-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
21. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 258760-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хезмәткә мобилизация буенча чакырылган затларның һәм махсус хәрби операциядә катнашучы затларның балаларының белем алуга аерым хокуклары хакында).
22. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә ирекле икътисадый зона турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү хакында» 326734-8 номерлы федераль закон проекты турында.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре, 2023 елның 13 апреле. № 1929-VI ДС

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Вакыт юк...

Бер карасаң, кызык инде бу дөнья. Үзебез дә кызык. Тирә-якка азга гына күз салсаң да, исләрең китәрлек бар – нәрсәләр генә уйлап тапмаган адәм акылы! Машина-тракторлары, компьютер-телефоннары, тормышны җайга салу өчен тәгаенләнгән башка нәрсәләре... Санап кына бетерерлек түгел. Чынлап та: «Кеше – дөньяда иң акыллы зат!» – дип күкрәк киереп мактанырлыгы бар. Без мактанабыз да инде. Тирәбездә йөргән эт-песиләр, сыер-сарыклар, тавык-казлар алдында. Гел кычкырып әйтмәсәк тә, күңелдә һәрвакыт шул горурлык хисе яши. Без акыллы. Акыллырак!

Гомумән, кешенең бөтен гомере, бөтен булмышы үзенең акыллырак, якты күңеллерәк, әйбәтрәк икәнен күрсәтергә тырышудан тора бугай. Өстенрәк икәнен, дисәң, дөресрәктер. Без моны яныбыздагы хайваннарга гына түгел, ә үзебез кебек үк ике аяклы мәхлукларга да расларга тырышабыз. Авызыбызны ачсак, акыллырак сүз әйтергә омтылабыз. Матуррак тавыш, саллы кыяфәт белән. Шул ук вакытта итагатьлерәк тә булырга. Шул ук вакытта дәрәҗәне дә сакларга. Бөтен яктан килгән, һәр яклап өстен, кыскасы. Чынбарлыкта без андый түгел инде, беркем дә күрмәгәндә әллә нинди сантыйлыклар, кыргыйлыклар кылып ташларга мөмкинбез. Ә кеше алдында...

Ә нәрсә ул – акыллы сүз? Әнә берәү урта гасырларда: «Җир әйләнә», – дигән. Бу дөрес һәм акыллы сүз булган, аны хәзер әллә ничә гасыр кабатлыйлар. Ә чордашлары шушы сүзен яратмыйча, аны учакта яндырганнар. Янындагылар сине утка салмасын өчен, әйткән сүзең аларның фикере белән тәңгәл килергә тиеш. Меңәр тапкыр кабатланып тапалып беткән фикер һәрвакыт акыллы сүз булып ишетелә. Сүзеңнең чынлап та акыллы булуы түгел, ә шулай ишетелүе мөһим. Әгәр дөрес сүзең дә ахмаклык булып ишетелә икән, димәк, ул – күпмедер дәрәҗәдә ахмаклык.

Кием кисәк, аның матуррагын, беркем дә кимәгәнен сайларга тырышабыз. Күз явын алып торсын инде, карап «аһ» итсеннәр. Шул ук вакытта ул үз гәүдәбезгә килешеп тә торсын, шул ук вакытта сыйфатлы да, уңайлы да булсын. Һәрьяклап килгән, кыскасы. Һәм без ихатада яки урамда эшләр майтарып кайтабыз да... Өстебездәге иске-москыны салып атабыз да... шул матур киемнәрне киеп фотога, я видеога төшәбез дә... социаль челтәрләргә эләбез. Чөнки үзеңнең өстенлегеңне бүтән җирдә күрсәтеп булмый. Ул матур киемнәрне киеп урамга чыгып китәсеңмени инде? Анда бит таныш-белешне очрату авыр хәзер. Алар күренми дә, күрми дә. Ә чит-ятларның күрсә дә исе китми. Ә интернетка куйсаң!..

Ризык пешерсәк тә шундый ук хәл. Ну, шәп килеп чыкты пәрәмәчең, төсе дә матур, исе дә. Хәтта тәме дә ничава. Һәрхәлдә, хөкүмәт ашханәсендә дә, шәхси ресторанда да бу тиклем итеп пешерә белмиләр. Димәк, син хөкүмәттән дә, бизнестан да өстенрәк. Аның дәлиле булып, пәрәмәчең өстәлдә балкып утыра. Үзең генә ашасаң, күңел булмый. Аны кемгәдер авыз иттерергә, һич югында күрсәтергә кирәк. Бөтен кеше дә күрсен дип, кунак җыеп ятып булмый бит инде. Вәт, фотога төшерәсең дә интернетка куясың. Күбрәк кеше күргән саен тәмләнә бара теге, матурлана. Үзең дә үзең өчен әллә кем булып тоеласың.

Бөтен өлкәдә дә шундыйрак без. Барлык гамәлебез үзебезнең өстенлекне күрсәтүгә корылган – уңганлыкны, матурлыкны, муллыкны, акыллылыкны, әйбәтлекне... Без һәрвакыт башкалар күзендә үзебездән дә яхшырак булып күренергә тырышып яшибез. Ләкин бөтен мәзәге шунда: без әйбәтрәк булырга теләмибез, без әйбәтрәк булып күренергә телибез. Барлык көчебез шуңа китә.

Ә моның өчен нәрсә кирәк? Сау-сәламәт кешегә? Юк, акча түгел... Вакыт, әлбәттә. Вакытың барда акча табып була, ә вакытны сатып алып булмый. Шуңа безнең вакытыбыз юк. Иртә таңнан чаба башлыйбыз, кара төнгә кадәр йөгерәбез. Анысы булсын, монысы булсын, дибез. Матур булсын, мул булсын, соклангыч булсын... Булсын!

Нәтиҗәдә... Менә болай килеп чыга. Без шушы «булсын»нарга алданып, «бар»ның кадерен белми калабыз. Өстәл тулы татлы нигъмәтләр бар – иркенләп, сөенеп ашарга вакыт юк. Гардеробта затлы киемнәр бар, ә без гел эштә, гел хәрәкәттә – матур киемнәр киеп йөрергә вакыт юк. Аяк астында балаларыбыз буталып, эшләргә мишәйт итеп йөри – башларыннан сыйпап узарга вакыт юк. Йортыбызда бәхет яши – аның белән ләззәтләнү түгел, хәлен белергә дә вакыт юк. Күңелләрдә якты тойгылар бар – хисне белдерергә вакыт юк. Акыл да бар. Тик уйларга безнең вакыт юк. Юк...

Адәм акылы үзе үк ахмаклыкның бер төре бугай ул.

vk.com

НИ ХӘЛЛӘРДӘ ЯШӘП ЯТАСЫЗ?

Авыл кәефе

Авылның үзгә бер рәхәт чагы. Кемдер бакчада казынып, җыештырып мәш килсә, кемдер яңа туган бозауга, кемдер сыерының күп итеп сөт бирүенә сөенә. Мобилизацияләнгән егетләрнең ялга кайтуы да авыл кәефен күтәреп җибәрә. Сыерчыклар сайравын, торналар җырын тыңлау да рухи көч бирә. Авыл кешесенә күп кирәкми. Эшләгәч, ашы да булачак. Ә сезнең кәефегез ничек?

Гөлсирә Шәрифуллина

Җир кешесенең эше бетәсе юк.

Әнвәр НИЗАМОВ, 98 яшьлек Бөек Ватан сугышы ветераны (Буа районының Яңавыл авылы):
– Кәефләрем әйбәт, кызым. Болай бик зарланмыйм әле. Җәйләрне көтеп алам. Үземә генә кышларны чыгу авыррак булыр. Яшик әле, күз күрер. Октябрьдә 99 тула, Алла боерса. Ел саен тәрәзә төбемә помидор үсентеләре утыртам. Әкренләп бакчада кыштырдап торам. Моңа кадәр машинам белән кибеткә кирәк-яракка да баргалый идем. Тик соңгы елларда табиблар йөрергә рөхсәт итми. Яшеңнең «срогы» чыккан, диләр. Йөрергә чамам бар үзе.

Халидә ГАБИДУЛЛИНА, Мөхәммәт Мәһдиев музее директоры:
– Масра басуларында нишләптер торна, кыр казлары күренми әле. Безнең тирәдә бик очмыйлар. Көн суытканга шулаймы, әллә безнең басуларга бөтенләй килмәүләреме, белмим. Башка елны бу вакытта бик күп очалар иде. Һава торышы да үзгәреп тора: әле кояш, әле суык.

Авылда көндәлек мәшәкать арта. Гөберчәк халкы да бакча тырмалау, чистарту, печән чәчү кебек эшләр белән мәшгуль. Зиратларда өмәләр көздән үткәрелә. Язын кеше үз туганнарының каберләрен чистарта.

Морис НӘГЫЙМОВ, бакчачы (Биектау районы):
– Бакчачылык белән шөгыльләнәм. Алмагач, груша сортларын сынап, безнең шартларга яраклаштырам. Грушаның «Лада», «Скороспелка из Мичуринска», «Чижовская», «Памяти Яковлева», «Августовская роса» сортларын үстерәм. Үсентеләрнең берсен 450 сумга сатам. Якынтирә авыллардан килеп алалар. Уңышы дөрес итеп утыртуга да бәйле. Шуңа күрә яхшылап аңлатып бирәм.

Илдар КӘБИРОВ, төзүче (Балтач районының Кили авылы):
– Бу көннәрдә мобилизацияләнгән дүрт егетнең өчесе – Илнар Шәрәфиев, Рәсим Нәҗмиев, Фәннүр Зарипов авылга ялга кайтты. Хәзер инде Илһам Нәфыйковны көтәбез. 100дән артык хуҗалыклы авыл өчен дүрт егетнең хәрби операциягә китүе күп инде. Авылдашлар белән аларны Казанга, район чигенә барып каршы алдык. Хәл белешеп, рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык. Шуннан да зуррак шатлык юк. Бераз моңсу да, чөнки китәр вакытлары җитте. Илнарны бергәләп озаттык инде. Барысы да тизрәк исән-сау әйләнеп кайтсын иде. Авыл халкы хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар ярдәм җыюда да актив катнаша.

Лилия ХӘЙРУЛЛИНА, хуҗабикә (Биектау районының Сая авылы):
– Сыерлар бозаулады, күп итеп сөт савабыз. Шуңа күрә кәефләр бик күтәренке әле. Авыл кешесенә күп кирәкми. Сөт продуктларын атнага биш тапкыр Казанга илтеп сатабыз. Катыгын да оетабыз, каймагын, эремчеген дә ясыйбыз. Сөтнең 1 литры – 50 сум. Әмма алучыларыбыз кимеде. Кеше акчасын кысып тота башладымы шунда, белмим. Артып калганын авылда 24 сумга тапшырабыз. Унбиш көн саен бәя ике сумга төшә бара. Сөт сатылмаганда, туйдым дип, ишекне бикләп, хөкүмәт эшенә чыгасы килә башлый. Икмәк, солярка бәясе күтәрелә, ә сөтнеке төшә.

Сарыкларның йонын ала башладык. Аны җыючы сирәк, саткан акчасына кайчы да тими. Бәясе бөтенләй юк дип, ачу килеп, кайчак мичкә дә яккалыйбыз.

Авылның үз проблемалары инде. Быел безнең шәхси хуҗалык көтүен көтәргә кеше юк. Электр көтүче куясы булырмы инде. Тирескә лицензия кертергә җыеналар. Авыл хуҗалыгын күтәреп, дотацияләрне, сөт бәясен арттырасы урынга, тузга язмаган нәрсәләр чыгаралар. Менә шуларын да уйлап яшибез.

Вакыйф ҖАМАЛИЕВ, пенсионер (Саба районы):
– Өй яшеллек белән тулды. Хатыным үсентеләрне күп итеп утыртты. Арада карбызы да бар. Сарымсаклар тишелде инде. Бөтен нәрсәне үзебез үстерәбез, кибеттән сатып алган юк. Орлыкка бәрәңге әзерләп куйдык. Бәрәңгене «Престиж» дигән препарат белән агулап утыртабыз. Колорадо коңгызы да килми, җан тыныч.

Авылда рәхәт. Сыерчыклар сайраганын тыңлыйм. Тиздән бала чыгарырлар. Ел саен аларны көтеп алам. Көн суыткач, балыкка йөреп булмый әле. Авыл тирәләрендә күп йөрим. Су буйларындагы пычракка эчем поша. Бакча артлары елга тирәсендә урнашкан хуҗалыкларны әйтүем. Кешеләр саламны инеш буйларына ыргыта. Шуны черетеп, бакчага таратсалар, булмыймыни? Анда ниләр генә юк. Сыер тиресе, сарык башы, тирес... Чисталык, культура дигән нәрсә кайда? Болай да елгада балыклар калмады бит инде. Үзең генә түгел, кеше турында да уйларга кирәк.

Сәрия МИФТАХОВА сораштырды

ЯШЬ ЮМОРИСТ ДИЛИЯР БОРҺАНОВ:

«ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ШАЯРУ ДӘРӘҖӘСЕН ЗЫЯЛЫ ИТӘСЕ КИЛӘ»

«Әйдә ШаяРТ» татар КВН лигасында КФУ студенты Дилияр БОРҺАНОВ жюрида утыручыларны да, тамашачыны да шаккатырды. Түбәтәй киеп сәхнәгә чыгып баскан егеттән әллә ни өмет итмәүчеләр дә булгандыр. Бәлки, юмор да татарча акцент, чәкчәк һәм чәйдән ары китмәс дип көткәннәрдер. Әмма «Дилүс улы» дигән командасы белән үзенчәлекле жанрда чыгыш ясап, халыкны көлдерде ул. Үзенчәлеге нидә дисәгез, җавап шул: команда бер генә кешедән, ягъни Дилиярдан гына тора.



Шәхси архивыннан

Егеттә ун кешене алмаштырырлык тел байлыгы да, мәзәк запасы да чиктән ашкан булып чыкты. Берничә минут дәвамында татарча мәзәкләре белән залны «кыздырган» егетнең тырышлыгын жюри әгъзалары да югары бәяләде. Узган елның кышында ул татарча КВН лигасының Гран-при иясе булды. Дилияр язгы уеннарда да көчен сынады, тиз арада тамашачының да, бәя бирүче жюриның да сөйкемле сөягенә әйләнде. Яшь юморист белән без дә җәһәт әңгәмә кордык.

:: Дилияр, татарда юмор бармы?
– Татарда юмор бар. Ләкин мине көлдерми. Яшьләрчә күзаллау җитми сыман. Минемчә, шаярсаң, заманага туры китереп шаярырга кирәк.

:: Ә синең мәзәкләрең ничек туа?
– Аралашуым татар эстрадасы артистларына бәйле булмагач, алар белән кызыксынмагач, мин татарларга, аларга бәйле очракларга, хәлләргә объектив карыйм. Чагыштыру алымын кулланам. Бу процесс барышында кызыклы хәлләрдә шаяру теләге туа. Иң яхшы шаяру ул – ирония, үз-үзеңнән көлә белү. Шуңа да татарча КВН сәхнәсенә чыгып, татар эстрадасы артистларына бәйле темаларга шаярттым.

:: «Әйдә ШаяРТ»та катнашу теләге ничек туды соң?
– Мин КВН белән күптәннән дус. 2019 елда Алабуга җыелма командасы белән чыгыш ясадым, русча чыгышларым да булды. Бер заман татфактан, команда җыеп, татарча КВНда катнашырга тәкъдим булды. Мин команда туплап өлгермәдем. Әмма җаваплылык хисе бар бит: үзем генә чыгыш ясарга булдым. Бу формат миңа бик ошады. Тамашачыны да җәлеп итте ул. Бу яңалык иде.

«Әйдә ШаяРТ»та шундый бер мизгел дә булды. Чыгышымнан соң жюрида утырган Айваз Садыйров (алып баручы, «Тәртип» радиосы башкарма продюсеры. – **Авт.**) яныма килеп: «Син нинди телдә фикер йөртәсең?» – дип тә сорады. «Татарча», – дидем. Әмма мин берничә көн бу хакта уйланып йөрдем әле. Бәлки, мин русча фикерлим һәм шул рәвешле татарча көчлерәк шаярамдыр?

:: Бездә нәрсә турында шаяртырга була, ә нәрсә хакында – юк?
– Минемчә, бөтен нәрсә турында да шаяртырга ярый. Үз алдыңа киртә кую хәерлегә илтми. Тыйнак булырга, куркырга кирәкми! Шаяру аша үз фикереңне, хисләреңне белдерергә кирәк.

:: Син татар телен бик яхшы беләсең, тәмен белеп сөйләшәсең. Телгә мәхәббәт каян килә? Яшьләр ана телендә сөйләшми бит, син яшьтәшләрең белән татарча аралашасыңмы?
– Туган телем – татар теленә мәхәббәтне әдәбият укытучысы буларак минем әнием уятты. Хәзерге вакытта мин дусишләрем белән татарча сирәк аралашам, монысы хак. Ләкин татар телен – ана телемне ярату миңа хәрәкәт бирә. Минем татарча шаярасым, татар телендә шаяру дәрәҗәсен зыялы итәсем килә.

:: Матбугат белән танышып барасыңмы? Яшьләрне җәлеп итү өчен, татар басмаларына ни җитми?
– Әлбәттә, матбугатны күзәтеп барам. Минем танышларым, төркемдәшләрем төрле редакцияләрдә практика уза, эшли. Мин дә читтә калмыйм. «Ялкын» журналы, «ТНВ» каналында практика узам. Яшьләрне кызыксындыру өчен, ни җитми, дигәндә... Бу – бик катлаулы сорау. Аңа кыска итеп җавап бирергә телим: яшьләр җитми.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ
- ★ Дилияр – Зәй егете.
- ★ «Сәләт», «Созвездие – Йолдызлык» һәм башка бик күп конкурс-фестивальләрдә чыныгу алган егет ул.
- ★ Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында татар теле, әдәбияты һәм журналистика факультетында белем ала. Тик киләчәктә журналист булу хыялы юк. Тәкъдим булса, телевидениедә юмористик тапшыру алып барырга тели.
- ★ Журналистика өлкәсенә игътибар итүенә Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимовның публицистик, тәнкыйди язмалары сәбәпче.

«Нур»лы тамашалар

Җырлы театр Казанга килә. Татарстан башкаласында «Нур» татар дәүләт театры гастрольләре башлана. Казанга килүне бәйрәм дә, имтихан тоту да, ди үзләре.

Гастрольләрдән кайтып та кергәне юк икән «Нур» театрының. Чаллы, Актаныш, Сарман һәм башка якын-тирә район-шәһәрләрдә еш кунак икән алар. Хәзер инде Казанга да чират җиткән. Уфа кунаклары Камал театры сәхнәсендә үз тамашаларын күрсәтәчәк.

Камал театры директоры Илфир Якупов әйтүенчә, бу – Уфа театрының Татарстан тамашачысы белән традицион очрашуы. «Без барлык милли театрлар белән даими элемтәдә торабыз, бергә эшлибез. Бер-беребезнең спектакльләренә йөрибез. «Нур» белән гадәткә кергән гастрольләрне пандемия бозды. Хәзер инде, шөкер, алмаш гастрольләрне яңадан торгызып, дәвам иттерәбез. Аларның спектакльләре Татарстан тамашачысы өчен кызыклы булыр дип уйлыйм. «Нур»лылар зур һәм кече сәхнәдә дә уйныйлар», – диде ул.

Соңгы елларда алмаш гастрольләр ике елга бер була. Бу арада ике як театрда да яңалыклар бар, репертуар яңара, үзгәрә. Димәк, сәнгатькә сусаган тамашачыга да сайлау мөмкинлеге арта.

«Нур» театры директоры Фирзәт Габидуллин сүзләренчә, гастрольләр 25 апрельдән башланачак. «Соң булса да, уң булсын. Ике ел саен йөреп торырга кирәк. Яңа спектакльләребез дә бар», – диде ул.

– Күтәренке рухны саклап калырга иҗат һәм театр ярдәм итә. Безнең тамашалардан халык буш китми. Алар рухи көч эзләп килә. Режиссер әйтергә теләгән сүз спектакльләрдә ачык яңгырый, – диде «Нур» театры әдәби бүлек мөдире Гөлнур Заһидуллина. – Тамашачы безнең афишадан үзенә кирәген сайлап алу мөмкинлегенә ия.

«Нур» труппасы мәктәпләрдә спектакль күрсәтергә дә җыена, очрашулар да көтелә. Танылган шәхесләрнең һәйкәлләренә чәчәк салуны да күздә тоталар.

«Нур»лылар нәрсә тәкъдим итә соң?
- 25 апрель – «Фатыйма»
- 26 апрель – «Көлмәгез, мин үләм», «Хыял йорты»
- 27 апрель – «Көлмәгез, мин үләм», «Бер мәл шәһәрдә»
- 28 апрель – «Галиябану»

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 254

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+